ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«11»август 2020 ел № 79-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районының күнегүләр һәм ярышлар процессларын
оештыру турында

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карарына нигезеләнгән «Күнегүләр һәм ярышлар процессларын оештыру турында» 2020 елның 04 августындагы 234 номерлы боерыгы, "Яңа коронавируслы инфекцияне (COVID-19) профилактикалау чаралары турында" Россия кулланучылар күзәтчелегенең 2020 елның 10 мартындагы 02/3853-2020-27 номерлы хатына хезмәткәрләр арасында яңа коронавируслы инфекцияне (COVID-19) профилактикалау буенча тәкъдимнәр нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы һөнәри командалары һәм спорт җыелма командалары әгъзалары белән күнегүләр һәм ярышлар процессларын оештыруны рөхсәт итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә:

2.1. Әгерҗе муниципаль районында күнегүләр һәм ярышлар барышын тәэмин итәргә;

2.2. хезмәткәрләр арасында коронавирус инфекциясен профилактикалау чараларын күрергә;

2.3. әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган яки күрсәтелгән нәтиҗәләрнең җитүенә куркыныч тудыра торган йогышлы авыруның таралуына китерә торган гамәлгә (гамәл кылмау) өчен җаваплылык турында кисәтүне оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының спорт һәм туризм эшләре бүлеге башлыгына әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының физик культура һәм спорт өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә җиткерергә.

4. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге порталы составында

Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И.И. Шәмсетдинов**